**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д. 1, с. Алан, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп ур., 1 нче йорт, Алан авылы, 422085
тел.: (84360) 54-1-13,
E-mail: Alan.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053621 ОГРН 1061675010176 ИНН/КПП 1619004387/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 9**

**КАРАР**
**22 март 2023 ел**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы “Алан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмеш лампаларын туплау урынын оештыру, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү турында**

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Энергияне сак тоту турында һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хакимиятенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы «Дөрес булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары ягыннан җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү Кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмеш лампаларын туплау урынын түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Теләче районы, Алан авылы , ҖЧ “Алан” ширкәтенең машина трактор паркында кирпич бинада, авылдан төньякта 0,5 км читтә билгеләргә.

2. Күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган, терекөмешле лампа кулланучыларда эшкәртелгән терекөмеш лампалар туплау урыннары Россия Федерациясе Хакимиятенең

2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Дөрес булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары ягыннан җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү Кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән эшкәртелгән терекөмеш лампаларын туплау урыннары күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган, терекөмешле лампа кулланучылар өчен дә билгеләнгән, әлеге күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен урыннар булмау сәбәпле, эшкәртелгән терекөмеш лампалар туплау урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракта.

4. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге территориясендә урнашкан эшкәртелгән терекөмешле лампаларны туплау урыннары турында кулланучыларга мәгълүмат бирергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының рәсми сайтында, район массакүләм мәгълүмат чарасында «Теләче» газетасына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Алан авыл җирлеге башлыгы Б.Н. Хәсәнов